| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 18.11.2022 | Казан ш. | № 599-173/кс-2022 |

«ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны чистартуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 10.12.2021 №494-152/кс-2021 карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023-2026 елларга җайга салынулы оешманың агынты суларны чистартуга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022-2026 елларга «ЗВКС» акционерлык җәмгыяте өчен агынты суларны чистартуга тарифлар билгеләү турында» 10.12.2021 №494-152/кс-2021 карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге таблица графаларын

| | |
|---|---|
| «01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 9,73 |

| | |
|---|---|
| 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 9,97» |

2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге таблица графаларын

| | |
|---|---|
| «01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 9,97 |
| 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 10,78 |
| 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 10,70 |
| 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 10,70 |
| 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 10,70 |
| 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 11,35 |
| 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 11,35 |
| 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 11,39» |

түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 10,47 |
| 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 10,47 |
| 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 10,91 |
| 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 10,91 |
| 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 11,30 |
| 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 11,30 |
| 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 11,78» |

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев